| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2019 Казан шәһәре № 10-220/кс

2020 елга «Суүткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Суүткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында җиткерелә торган кайнар суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Суүткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыятенә иректе файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу

чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.
кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2019 № 10-220/кс карарына кушымта

Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Сууткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында җиткерелә торган кайнар суга 2020 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек исеме, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тариф (ике компонентлы) | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м. | | Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал | |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Су үткәрү-канализацияләү һәм энергетика хуҗалыгы» акционерлык җәмгыяте | | | | |
| 1.1. | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 25,07 | 25,07 | 1651,46 | 1717,52 |
| 1.2. | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 20,89 | 20,89 | 1376,22 | 1431,27 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге